**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Юшады авыл җирлегенең Түбән Юшады торак пунктында
2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**20.11.2023ел.** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» "06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегенең Түбән Юшады авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге Түбән Юшады торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2024 елда 2000 сум күләмендә үзсалым кертергә *1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, күп балалы гаиләләр, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.*

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

-Түбән Юшады торак пунктына керү өчен авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Юшады авыл җирлегенең мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән әлеге карарны Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://menselinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Юшады авыл җирлеге башлыгы ____________ И.Р.Ханов
(имза)

Совет
ЮШАДИНСКОГО
сельского поселения